Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР №XI-6**

Балык Бистәсе штп. 2021 елның 31 августы

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2013 елның 4 апрелендәге XXVI-3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатларында, “Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 2021 елның 16 июлендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2013 елның 4 апрелендәге XXVI-3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 22.07.2013 ел № XXVII-6, 14.08.2014 ел №XXXIX-3, 13.12.2014 ел № XLII-8, 14.11.2015 ел №V-3, 23.04.2016 ел №X-8, 16.11.2016 ел №XIII-9, 29.05.2017 ел №XIX-9, 23.10.2017 ел №XXII-6, 24.07.2018 ел №XXXII-4, 19.11.2018 ел №XXXVI-5, 20.12.2018 ел № №XXXVII-2, 01.04.2019 ел №XLI-11, 22.07.2019 ел №XLIV-4, 24.09.2019 ел №XLV-13, 17.02.2020 ел №L-4, 05.08.2020 ел №LIV-9, 06.10.2020 ел №II-1, 28.06.2021 ел №X-4 карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 маддәнең 5.5 өлешендә:

а) 9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“9) Россия Федерациясе гражданлыгын яисә Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә катнашучы чит илнең гражданлыгын (подданствосын) (аның нигезендә чит ил гражданы муниципаль хезмәттә булырга хокуклы) туктату турында яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) язма рәвештә муниципаль хезмәткәргә бу турыда билгеле булган көнне хәбәр итәргә, әмма Россия Федерациясе гражданлыгы яисә Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә катнашучы чит илнең гражданлыгы (подданствосы) (аның нигезендә чит ил гражданы муниципаль хезмәттә булырга хокуклы) туктатылган көннән алып биш эш көненнән дә соңга калмыйча;”;

б) түбәндәге эчтәлекле 9.1 пунктын өстәргә:

“9.1) чит дәүләт гражданлыгы (подданствосы) алу турында яки яшәүгә рөхсәт кәгазе яисә гражданның чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслаучы башка документ алу турында яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) язма рәвештә муниципаль хезмәткәргә бу турыда билгеле булган көнне хәбәр итәргә, әмма чит дәүләт гражданлыгы (подданствосы) алу турында яки яшәүгә рөхсәт кәгазе яисә гражданның чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслаучы башка документ алган көннән алып биш эш көненнән дә соңга калмыйча;”;

2) матдәнең 6.1 өлешендә:

а) 6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“6) Россия Федерациясе гражданлыгын яисә Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә катнашучы чит илнең гражданлыгын (подданствосын) (аның нигезендә чит ил гражданы муниципаль хезмәттә булырга хокуклы) туктатуның ;";

б) 7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“7) әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә башкасы каралмаган булса, чит дәүләт гражданлыгы (подданствосы) яки яшәүгә рөхсәт кәгазе яисә чит ил территориясендә гражданның даими яшәү хокукын раслый торган башка документ булуның;";

3) 10 матдәнең 10.4.1 өлешендәге 2 пунктын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы

И.Р. Тажетдинов